**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮГАРЫ ЯХШЫЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

423765, Югары Яхшый авылы,
Яна урам,18 нче йорт.
Тел.885552 3-44-45.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ**
**РАЙОН РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
**ВЕРХНЕЯХШЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ**

423765, с. Верхнее Яхшеево,
ул. Новая, дом 18. Тел. 885552 3-44-45.
E-mail vyah.akt@yandex.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«17» январь 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлегендә балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиянең 2020 елга эш планын раслау турында

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 14.10.2011 № 71-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Югары Яхшый авыл җирлеге Уставы нигезендә, балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау, гаиләләр белән профилактик эш алып бару максатыннан
КАРАР БИРӘ:

1. Югары Яхшый авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссиянең эш планын (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми pravo.tatar.ru сайтында, Югары Яхшый авыл җирлеге http://aktanysh.tatar.ru/rus/aktanysh/poselenia сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Югары Яхшый авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Ж. Г. Зиннатуллина

Югары Яхшый авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесенең
17.01.2020ел №2 карарына
кушымта

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең 2020нче елга эш планы

| № п/п | Мероприятие | Үтәү вакыты | җаваплы | Кем белән берлектә үткәрелә |
|---|---|---|---|---|

Оештыру-методик эш

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышы (Татарстан Республикасы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районындагы беркетмәләре һәм күрсәтмәләре буенча балигъ булмаган балаларга һәм аларның ата-аналарына карата материалларны карау, белем бирү учреждениеләре тәкъдимнәре һәм үтенечнамәләре, гражданнарның шикаятьләре, торак шартларын тикшерү актлары һ. б.) | Кварталга 1 тапкыр | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 2. | Югары Яхшый авыл җирлеге авылларында КДН һәм ЗП күчмә утырышларын үткәрү | Квартал саен | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 3. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рейдлары | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 4. | Балигъ булмаганнар арасында эчкечелекне кисәтү максатыннан яшүсмерләр концентрациясе урыннары | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | (дискотекалар, урамнар) буенча рейдлар | | | |
| 5. | Сәүдә нокталары буенча рейдлар | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 6. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы КДН һәм ЗП утырышларында чыгарылган штрафлардан качып йөрүче гражданнар буенча рейдлар | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 7. | Имин булмаган гаиләләрне ачыклау һәм аларны КДН, ЗП һәм ПДНда исәпкә кую | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 8. | Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча яшүсмерләр һәм аларның ата-аналарын кабул итү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 9. | Гаилә көненә, Балаларны яклау көненә, Яңа елга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышында карау өчен чыгарылган мәсьәләләр

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларның һәм җинаятьләрнең торышы турында | Квартал саен | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 2. | Дәресләргә йөрмәгән балалар турында һәм мондый очракларга юл куймау буенча җирлек мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрелгән чаралар һәм балигъ | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составы турында мәгълүмат | | | |
| 3. | Яшәү урыны буенча Балигъ булмаганнарның ялын оештыру турында | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 4. | Күп балалы һәм имин булмаган гаиләләр белән эшләү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 5. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия эшенә йомгак ясау | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |